Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге Советы

**КАРАР №16**

Яңа Арыш авылы 2019 елның 18 декабре

Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге Советының
«Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлегенең 2020 елга
һәм 2021-2022 елларның план чорына
бюджеты хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсындагы 10 өлешенең 2 пункты нигезендә», Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 маддәләре белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсындагы 8 өлешенең 2 пункты, Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Уставының 19 маддәсе 2 өлешенең 3 пункты һәм 70,71 мадәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

**1 нче маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 2463,0 мең сум күләмендә;
2) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2463,0 мең сум.;
3) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджеты дефициты 0,0 мең сум.

2. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының 2021 елга һәм 2022 елга төп характеристикаларын расларга:
1) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең 2021 елга фаразланган гомуми кереме 2513,2 мең сум һәм 2022 елга 2571,1 мең сум күләмендә;
2) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең 2021 елга бюджет чыгымнарының гомуми күләме 2513,2 мең сум., шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 62,83,0 мең сум күләмендә, һәм 2022 елга 2571,1 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 128,6 мең сум күләмендә;

3) Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджеты дефицитының чик күләме 2021 елга 0,0 мең сум, 2022 елга 0,0 мең сум
3. 2020 елга һәм 2022 елның план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджет дефицитын финанслау чыганакларын 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

**2 нче маддә .**

1. 2020 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

2. 2021 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

3. 2022 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

**3 нче маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетында 2020 елга һәм 2022 елның план чорына фаразланган керем күләмен, 2 нче кушымта нигезендә, исәпкә алырга.

**4 нче маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 нче маддә.**

1. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан маддәлары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына чыгымнарының ведомство структурасын 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетының 2020 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә 10,2 мең сум һәм 2021 елның план чорына 10,3 мең сум һәм 2022 елга 10,5 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

**6 нчы маддә.**

1. 2020 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен 1720,00 мең сум, 2021 елга 1750,40 мең сум, 2022 елга 1794,8 мең сум күләмендә расларга.

**7 нче маддә.**

1. 2020 елга җирлекләр бюджетларының балансслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итү өчен җирлек бюджетларына дотацияләр күләмен 6.0 мең сум, 2021 елга-6,0 мең сум, 2022 елга 6,0 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**8 нче маддә.**

1. Территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен 2020 елга хәрби комиссариатлар булмаган урыннарда 92,0 мең сум һәм 2021 елның план чорына 92,2 мең сум, 2022 елда 93,6 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**9 нчы маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитеты 2020 нче елда һәм 2021- 2022 нче елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**10 нчы маддә.**

1. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының казначылык органнары төзегән килешүләр нигезендә Яңа Арыш авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**11 нче маддә.**

1. 2020 елның 1 гыйнварында Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге бюджеты акчалары, 2020 елның 1 гыйнварында, Балык Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге исеменнән 2019 елда шушы муниципаль контрактлар нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзегән өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, 2020 елда Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**12 нче маддә.**

1. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**13 нче маддә.**

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе

районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп  урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге
Советы рәисе Х.С.Зарипов